СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 11 июненнән № 40-139

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге советы 3.11.2023 № 33-119 карарына үзгәрешләр кертү турында «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге советы 3.11.2023 № 33-119 карарына «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас алынмаган очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычлары булу;»;

1.2. Карарның 1 өлешендәге 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар өчен җирле салымнар буенча 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган бурыч булу;»;

1.3. Карарның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
«5) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар узгач физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.».

2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда әлеге карарны бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https:/novoseshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы

Җ.Г. Гайфетдинов